СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 19 » октябрь 2017 ел № 1

**Төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Кәче авыл җирлеге Уставы, Кәче авыл җирлегендә, Кәче авыл җирлеге Советының 2009 елның 19 октябрендәге 11 номерлы карары белән (2012 елның 08 февралендәге 44 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Кәче авыл җирлегендә халык хокукларын муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1.Кәче авыл җирлеге Советының Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларын 07.11.2017 елга билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны Кәче авыл җирлеге Советының «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча 10.00 сәгатьтә ТР, Арча муниципаль районы, Кәче авылы, Үзәк урамы, 200 йорт адресы буенча үткәрергә.

3. Кәче авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә тәкъдим ителә торган үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, искәрмәләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалары язмача рәвештә 16 сәгатькә кадәр җибәрелә дип билгеләргә. 07.11.2017 елга кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР, Арча муниципаль районы, Кәче авылы, Үзәк ур., 20 йорт., тел.88436652393.

4. Әлеге карарны һәм Кәче авыл җирлеге Советының «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карары проектын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Т.Д. Закиров